

20 апрельдә Большие Поляны топ мәктәбе базасында Кадошкино районында беренче тапкыр аерым Туган татар теле коне vтте. Алдагы елларда «День родного языка» торле милләт вәкилләре белән бергә vтә иде. Кичәгә район һәм мәгариф бvлеге житәкчеләре, мәктәплләрдән торле милләтле директорлар һәм телчеләр жыелган иде.
Туган тел конендә зур программа белән Большие Поляны топ һәм Латышовка урта мәктәп укучылары белән укытучылары, авыл интеллигенциясе вәкилләре чыгыш ясадылар. Кvргәзмәләрендә Габдулла Тукаебыз туган конен искәртеп ясалган стендлар эленгән, кул эшләре белән тулган иде. Презентацияләре киләчәк буынны милли- мәдәни рухта тәрбия бирv турында булды.      Һәрбер милләтнен vз мәдәнияты, гореф-гадәтләре, vзенчәлекләре бар. Аларны бер-берсеннән шул vзен-чәлекләр аера да. Нәкъ шулар халыкны туган теле белән горурланырга, аны яратырга мәжбур итә. Большие Поляны һәм Латышовка мәктәпләрендә ел саен «Туган тел» кичәләре vткәрелә – традиция. Ә быел форматы vзгәрде, район статусын алды.



- Без татарлар, туган телебез - татар теле.Татар теле тугач та, ин газиз кешеннән ишетә башлаган, кvп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, 7 миллион халык сойләшкән, чит илләрдә дә ойрәнелә торган, бvгенге кондә житлеккән, камилләшкән, теләсә нинди катлаулы фәнне ойрәтергә момкинлеге булган, ин-ин авыр кимсетvләргә дә тvзгән, сынмаган-сыгылмаган, горур татар теле! Бvгенге кичәбезне сина багышлыйбыз, - дип ачып жибәрделәр кичәне алып баручылар. Аннары «Туган тел»

жырын Алсу Тумпарова һәм Дарина Кильдеева башкарды. Мәдәният йорты хезмәткәре, авыл сандугачы Надия Капкаева «Кайтырмын» жырын матур иттереп жырлады. Тумпаровларнын гаилә дуэты: Альфия белән Алсу «Авылым урамнары» дигән жырны атаклы жырчылар Алсу белән Фәридәдән бер дә ким башкармадылар. Яшь артисткалары Дарина Кильдеева башкарган «Әнием» жыры кvнелләрнен ин нечкә почмакларына кереп, хисләргә чумарга мәжбур итте. Тагы бу бәйрәмдә Большие Поляны мәктәбе укучыларынын әниләре белән әбиләре дә чыгыш ясадылар. Авылнын «Асылъяр» дигән vзэшчән сәнгать коллективы «Дусларыма» жырын жырладылар. «Дуслык» ансамбле составындагы Большеполянка мәктәбе укытучылары «Туган авыл» жырын матур жырладылар.
Зәнгәр кvк йозендә кояш балкыган чакта, шаулап-горләп апрель ае килгәндә, безнен яраткан шагыйребез Габдулла Тукай туган. Рус халкынын Пушкин вә Лермонтов кебек vк безнен Тукаебыз да vзенен кабатламас ижаты белән боек һәм даһи. Атаклы шагыйребез Габдулла Тукай татар мәдәниятын рус һәм донья мәдәниятына, башка милләтләр, аларнын телләре белән якынаерга кирәклеген анлаган: «Нам издавна другом был русский народ. И разве конец этой дружбе придет? Да, мы родились и растем в вышину. Нанизаны словно на нитку одну».



Башлангыч сыйныф укучылары Габдулла Тукай турында һәм анын шигырьләрен яттан матур иттереп башкардылар. Габдулла Тукай турында эчтәлекле презентация дә кvрсәтелде. Зур бәйрәмдә югары сыйныф укучылары «Рәхмәт әнкәй» жыры белән чыгыш ясадылар. Алтынчы сыйныф укучысы Регина Тумпарова гаиләсе турында сойләде. Бу гаиләдә барысы да туган татар телендә сойләшәләр. Бишек жыры белән кергән тел, ди эчтәлекле чыгышында Регина. Кечкенәдән милли гореф-гадәтләрне, мәдәниятны сакларга ойрәтvчеләр дә әбиләре белән бабайлары, әтисе белән әнисе анын. Тагы ул әнисе белән милли бәйрәмнәрдә милли ашамлыклар пешерешеп кунакларны каршы ала. Шулай кечкенәдән ук милли рухта тәрбияләнә.
Бәйрәмне тагы да ямьләтvчеләр - Латышовка урта мәктәбе укучылары чыгышлары булды. Алар шигырьләр сәнгатьле иттереп сойләделәр, кvнелләрне жилкендергән жырларны башкардылар. Шулай, сигезенче сыйныф матуркайлары Алина Алыкова, Регина Донская, Диана Симаева, Алсу Хайрова бергәләшеп жырласалар, Юлия Семечкина «Әниемә» дигән жырны ялгыз башкарды. Милләтебезнен боек улы – татар әдәбияты классигы, шагыйрь, публицист, яна заман татар әдәбиятына һәм әдәби теленә нигез салучы Габдулла Тукайнын (1886-1913) апрельдә туган коне, дидек. Халык шагыйре Габдулла Тукай доньяга килгән (26) һәм хушлашкан апрель(15) аенда. Халык

аны олылый, боекли; инде ничә буын аны онытмый. Мордовиянен барлык татар мәктәпләрендә, гадәттәгечә, Тукай туган конендә Шигърият бәйрәмнәре уза. Егор Максимкин Габдулла Тукайга багышлап «Ул мәнге безнен кvнелдә» шигырен сәнгатьле сойләде. Телләрен, мәдәниятларын чынлап ярата икән бу балалар.
- Туган тел бәйрәмен vткәрәбез, шунын белән без доньядагы телләргә, аларнын мәдәниятына мәдхия жыр-лыйбыз. Телләребез торле, теләк-ләребез бер; телләребез - бvләккә тапшырылган мирас, без аны сакларга тиешбез, - ди аралашканда татар теле укытучысы Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева.
Кичә бергәләшеп Г.Тукай сvзләренә язылган «Туган тел» жырын башкару белән тәмамланды.

**Наилә Насырова**